Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”

«Каралды»
Педагогик киңәшмә
утырышында

Беркетмә №1 «30 » августтан 2023 ел.

«Расланды»
Беркетмә №79 «30 » августтан 2023 ел.

Директор
__________/М.Г. Макарова /

**Әдәби укудан ( татар әдәбиятыннан)**
**эш программасы**

Белем бирү баскычы: башлангыч гомуми, 1-4 нче сыйныфлар

**Башкарылды**: башлангыч сыйныф укытучыларының
мәктәп методик берләшмәсе

Менделеев шәһәре, 2023 ел

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1-4 сыйныфлары өчен әдәби укудан эш программасы башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә *туры китереп*,Ф.Ф.Хәсәнованың “Татар телендә белем бирүче гомуми белем оешмалары өчен татар әдәбияты фәне буенча үрнәк эш программасы (“Әдәби уку”, 1-4 нче сыйныфлар) на *нигезләнеп*, Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллинаның «Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә әдәби уку» предметын укыту программасы.1–4 нче сыйныфлар” авторлык программасын *исәпкә алып* төзелде.
Дәреслекләр:

| Дәреслек исеме | Сыйныф | Авторы | Нәшрият |
|---|---|---|---|
| Әлифба | 1 | И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Р.Р. Шәмсетдинова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек. 1 нче сыйныф. | 1 | Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ә.МГ. Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф. Хәсәнова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек-хрестоматия. 1 нче сыйныф. | 1 | Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ә.МГ. Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф. Хәсәнова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 2 нче сыйныф. | 2 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек-хрестоматия. 2 нче сыйныф. | 2 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 3 нче сыйныф. | 3 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г. Мөхәмәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек-хрестоматия. 3 нче сыйныф. | 3 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г. Мөхәмәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 4 нче сыйныф. | 4 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Әдәби уку. Дәреслек-хрестоматия. 4 нче сыйныф. | 4 | Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |

Эш программасы барлыгы 138 сәгатькә сәгатькә, атнаг 1 сәгатьтән төзелде (1сыйныф – 33 сәг., 2 сыйныф – 35 сәг., 3 сыйныф – 35 сәг., 4 сыйныф – 35 сәг.)

**Курсның шәхси, метапредмет һәм предмет үзләштерү нәтиҗәләре**
**1 сыйныф**
**Шәхси нәтиҗәләр:**

Укучыда формалашачак:
- туган ил, халкың һәм тарих өчен горурлык хисе кичерү;
-үзеңнең милли һәм этник яктан кая керүеңне аңлап, рухи кыйммәтләр булдыру;

- дөньяга, аның табигать, халык, мәдәният, дин бергәлегенә карата тулы, социаль юнәлештәге караш ;
- башка фикерләргә дә хөрмәт белән карарга өйрәнү;
- башкаларның хис – тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы – шатлыгын уртаклашу;
-үзең өчен җаваплылык хисе һәм мөстәкыйлллелекне үстерү;
- өлкәннәр һүм яшьтәшләрең белән төрле социаль ситуацияләрдә хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерү

*Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*
- *өлкәннәр һүм яшьтәшләрең белән төрле социаль ситуацияләрдә хезмәттәшлек итү күнекмәләрен;*
- *бәхәсле ситуацияләрдән чыгу юлын табу сәләтен булдыру;*
- *куркынычсыз, сәламәт яшәү рәвеше алып бару,*
- *материаль һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл караш формалаштыру.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып -белү УУГ**

Укучы өйрәнәчәк:
- укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләргә һәм формалаштырырга;
- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнергә;
-дәреслек белән эш итә белергә;
- хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп укырга;
- этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап укырга;
- текста очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә;
-текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирергә;
-укытучының сорауларына җавап бирергә, тиешле мәгълүматны таба белергә;
- информация табу өчен төрле эзләү төрләре , җыю, эшкәртү, анализ, оештыру, тапшыру кулланырга.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
- *предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели бел*ергә*;*
- *укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген кыскартып яки, тулыландырып сөйли бел*ергә*;*
*итә белү (линейка, карандаш, бетергеч…) һәм өстәмә чаралар (информацион һәм коммуникацион технологияләр, белешмә әдәбият һ.б.) куллана бел*ергә*;*
- *эш сыйфатына бәя бирә бел*ергә*;*
*-уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба бел*ергә.

***Коммуникатив УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:
- аралашу һәм хезмәттәшлек итәргә;
- бергә утырган иптәшең белән бергә эшләү: эшләрне килешеп үзара бүлешү, үз эшеңне кеше ярдәменнән башка башкару, бер-береңең башкарган эшне тикшерә белергә;
- эшләрне чылбырлап башкарырга;
- төрле фикерләр арасындагы аерманы ишетеп аңлау һәм килешергә.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
- *уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;*
- *күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;*
- *күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга;*
- *сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә.*

***Регулятив УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:
- бер үк сорауга төрлечә җавап бирү мөмкин икәнлеген аңларга;
--үз фикереңне дәлилләү өчен уку китабыннан мисалларга мөрәҗәгать итәргә;
- үзанализ һәм үзбәя булдырырга.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
- эшчәнлек өчен эш урынын әзерләргә;

- укытучы ярдәме белән уку проблемасын табарга һәм формалаштырырга;
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнергә;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерергә.

**Предмет нәтиҗәләре**.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Укучы өйрәнәчәк:
- ишеткән сөйләүне кабул итү (әңгәмәдәшеңнең фикерләрен, төрле текстларны укыганда тыңлый белергә;
- сөйләм барышында әйтелгән фикерне аңлау, ишеткән әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә.

*Укучыга үзләштерергә мөмкинлек бирелә:*

*Вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләүне, сөйләмдә куелган максатны аңлый алуны, дөрес, фәнни яктан танып-белүне, әдәби әсәрләрне тыңлаганнан соң сораулар куя белүне .*

**Сөйләм һәм уку эшчәнлегенең төрләре**

Укучы өйрәнәчәк :
- иҗекләп һәм сүзләр белән, өзлексез салмак тавыш һәм билгеле бер темп белән кычкырып укырга;
- кычкырып укыган кечкенә күләмле әсәрләрнең эчтәлеген ишетеп аңларга, алардагы логик өлешләрне аерып әйтә белергә;
- текстның билгеләгән өлешләрен аерып алып эчтән укырга һәм укыган өлешләрнең төп фикерен аңларга;
- төрле авторларның 3-4 шигырен яттан сөйләргә.

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

-*“Эчтәлек” битен файдаланырга;*
- *дәрестә текст белән эшләү өчен өстәмә хрестоматиядән, өйдән алып килгән китаплардан файдаланырга;*
-*әсәр эчтәлеге буенча сораулар төзү һәм бирелгән сорауларга җавап бирергә.*

**Әдәбият белеменә кереш**

**Сәнгатьнең төрле төрләренә караган әсәрләр белән эшләү (әдәбият, рәсем сәнгате, гамәли сәнгать,сынлы сәнгать, музыка һ.б)**

Укучы өйрәнәчәк :
- шигъри әсәрләрне чәчмә әсәрләрдән аера белергә;
- фольклор әсәрләренең кече жанрларын аерырга: табышмак, санамыш, тизәйткеч, атамыш;
- тексттагы тел-сурәтләү чараларын таба белергә (кабатлау, сүзләрнең иркәләү-назлау формалары, өндәү һәм сорау билгеләре, рифмалар).

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *әдәби әсәрләр белән х.а.и. әсәрләре арасында күчешле чикләрне табарга (хикәядә кулланылган әкият элеиентлары, тылсымлы әкиятләргә хайваннар турындагы әкиятләрнең кушылып китүе һ.б.)*
- *балалар өчен авторлар иҗат иткән поэтик әсәрләрдә фольклор жанры үзенчәлекләрен табарга: әкият-чылбырларның сюжет-композицион үзенчәлекләре, санамышлар, тизәйткечләр, атамышлар, бишек җырлары*

**Иҗади эшчәнлек элементлары**

Укучы өйрәнәчәк :
- укыганның эчтәлеген аңлау, тиешле интонацияне, уку темпын һәм тиешле тукталышларны текст эчтәлегеннән чыгып аңлап сайлый белергә,
- әдәби әсәрләрнең өлешләрен рольләргә бүлеп һәм чылбырлап укырга;
- иллюстрацияләрне карау, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер (хисләр, кичерешләр) белән тәңгәлләштерергә.

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *шигъри һәм чәчмә әсәрләрне сәнгатьле итеп укырга;*

- *дәреслектәге иллюстрацияләрне карау, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер (хисләр, кичерешләр) белән тәңгәлләштерергә;*
- *үзеңнең шәхси кичерешләрен һәм күзәтүләреӊ белән телдән уртаклаша белергә.*

**2 нче сыйныф**

**Шәхси нәтиҗәләр**

Укучыда формалашачак:
- укуга уңай караштa булу, укырга теләкбелдерү, яңа биремнәрне чишү ысулларына, автор белән кара-каршы сөйләшүгә кызыксыну;
- эстетик тойгыларын үстерү; яңа материалга танып-белү кызыксынуы;
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую) .

*Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*
- *әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;*
- *текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*
*“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

***Танып-белү УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:
- дәреслектә укый торган китапта бирелгән шартлы билгеләрне укый белергә, кирәкле текстны китапның “Эчтәлек” бүлегеннән карап таба белергә;
- текстның билгеләнгән һәм кирәкле өлешләрен, юлларын, сүзтезмәләрен, сүзләрен бик тиз таба белергә;
- мәгълүмат алуның берничә чыганагы белән берьюлы эшли белергә ( уку китабы, мөстәкыйль эшләү өчен эш дәфтәре һәм хрестоматия; уку китабы һәм сүзлекләр; текстлар һәм текстка иллюстрацияләр).

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
- *объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләргә;*
- *төп мәгълүматны аерырга, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белергә;*
- *төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштырырга;*
- *материаль объектлар кулланып биремнәр үтәргә.*

***Регулятив УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамларга;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерергә;
- тормыш тәҗрибәсен кулланырга;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә;
- әйтелгән фикерне тексттан өзекләр яки җөмләләр белән дәлилләргә;
- төрле фикерләрнең төрле нигезләре булырга мөмкин икәнлеген аңларга.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
- *эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештырырга, нәтиҗәле эш алымнарын таба белергә;*
- *уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белергә;*
- *билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белергә.*

***Коммуникатив УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:
- аралашу һәм хезмәттәшлек итәргә;

- бергә утырган иптәшең белән бергә эшләргә: эшләрне килешеп үзара бүлешергә, үз эшеңне кеше ярдәменнән башка башкарырга, бер-береӊ башкарган эшне тикшерә белергә;
- эшләрне чылбырлап башкарырга;
- төрле фикерләр арасындагы аерманы ишетеп аңларга һәм килешергә;
- тексттан геройлар әйткән фикерләрнең дөреслеген дәлилли торган фикерләрне табарга.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;*
- *күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;*
- *күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга;*
- *сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә.*

**Предмет нәтиҗәләре**

**Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре.**

Аудирование, эчтән һәм кычкырып уку, төрле төрдәге текстлар белән эшләү, библиография белән эшли белү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү, аралашу культурасы.

Укучы өйрәнәчәк:

- уку тизлеген арттыра барып, сүзләрне тулы әйтеп кычкырып укырга;
- текст белән беренчел танышканда, өлешләп укыганда һәм кабатлап укыганда эчтән укырга;
- укыган текстка карата кыскача монологик фикерләмә 6 укытучы соравына кыска һәм тулы җавап бирергә;
-әңгәмәдәшеңне (укытучыны, сыйныфташыңны) тыңларга: әйтелгән фикерне кабатламау, башкалар әйткән фикерне тулыландыру;
- татар әдәбиятының 2-3 классигының исемен әйтергә, әсәрләрнең исемнәрен атарга һәм кыскача эчтәлекләрен сөйләргә;
- яраткан язучын турында әйтә белергә һәм аның әсәрләрен атарга, аларның эчтәлеге турында кыскача гына әйтә белергә;
- әсәрнең төп темасын һәм фикерен (укытучы ярдәме белән) аерып чыгарырга;
- әсәрдәге геройларга (исемнәрен атау, портреты, сөйләме) һәм аларның гамәлләренә бәя бирергә;
- сүзләрнең мәгънәсен ачыклау өчен аңлатмалы сүзлекбелән эшли белергә.

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *укытучы укыган текстны ишетеп аңлау күнекмәләрен үстерергә;*
- *укыган әсәр эчтәлегенә телдән үзенең фикерен белдерергә;*
- *сайлап алып 2-3 авторның шигырен сөйләргә;*
- *зур булмаган текстны сөйли белергә;*
- *китапханәдән китаплар һәм вакытлы матбугат сайлаганда, тышлыкка карап сайларга, шулай ук китапларның "Эчтәлек" битен файдаланырга;*
- *дәрестә текст белән эшләү өчен өстәмә хрестоматиядән, өйдән алып килгән китаплардан файдаланырга;*
- *әсәр эчтәлеге буенча сораулар төзү һәм бирелгән сорауларга җавап бирергә.*

**Әдәбият белеменә кереш**

**Сәнгатьнең төрле төрләренә караган әсәрләр белән эшләү (әдәбият, рәсем сәнгате, гамәли сәнгать,сынлы сәнгать, музыка һ.б)**

Шигъри әсәрләрнең үзенчәлекләрен белү (ритм, рифма һ.б), жанр үзенчәлекләрен аеру ( халык авторлар иҗат иткән әкиятләр),әдәби алымнарны тану (чагыштыру, сынландыру, каршы кую һ.б.)

Укучы өйрәнәчәк:

- тылсымлы әкиятләрне хайваннар турындагы әкиятләрдән аерырга;
- т ылсымлы әкиятләрнең үзенчәлекләрен аерырга;
- әкиятләрне хикәяләрдән аерырга.

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

*- балалар өчен авторлар иҗат иткән поэтик әсәрләрдә фольклор жанры үзенчәлекләрен табарга: әкият-чылбырларның сюжет-композицион үзенчәлекләре, санамышлар, тизәйткечләр, атамышлар, бишек җырларын;*
*- әдәби әсәрләр белән х.а.и. әсәрләре арасында күчешле чикләрне табарга (хикәядә кулланылган әкият элеиентлары, тылсымлы әкиятләргә хайваннар турындагы әкиятләрнең кушылып китүе һ.б.)*
*- дөньяны танып-белүнең шигъриятен тоярга;*
*- дөньяны тоюдагы шигъри хисләрнең тезмә әсәрләрдә (шигъри текстларда ) генә түгел, чәчмә әсәрләрдә дә бирелүен.*

**Иҗади эшчәнлеге элементлары.**

Рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү, телдән тасвирлау, репродукцияләр белән эшләү.
Укучы өйрәнәчәк:
**- укыганның эчтәлеген аңларга,**
- тиешле интонацияне, уку темпын һәм тиешле туктальшларны текст эчтәлегеннән чыгып аңлап сайлый белергә,
- әдәби әсәрләрнең өлешләрен рольләргә бүлеп һәм чылбырлап укырга;
- программада бирелгән матур әдәбият әсәрләрен эмоциональ (хис белән) кабул итәргә.
*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
*- шигъри һәм чәчмә әсәрләрне сәнгатьле итеп укырга;*
*- дәреслектәге иллюстрацияләрне карарга, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер (хисләр, кичерешләр) белән тәңгәлләштерергә;*
*- үзеңнең шәхси кичерешләрен һәм күзәтүләрең белән телдән уртаклаша белергә.*

**3 нче сыйныф**

**Шәхескә нәтиҗәләр**

Укучыда формалашачак:
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың,уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- аилә әгъзаларына, гаилә кыйммәтләренә ихтирам һәм хөрмәт белән карау; башкаларның хис -кичерешләрен аңлау, аларга карата мәрхәмәтлелек һәм киң күңеллелек күрсәтә белү;үзеңнең һәм башкаларның холкына, тотышына әхлак нормалары югарылыгыннан бәя бирү.
*Укучы формалашырга мөмкинлек алачак:*
*- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ;*
*- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып-белүУУГ**

Укучы өйрәнәчәк:
- дәреслектә ориентлаша белергә;
- сүзлекләр белән җиңел эшләргә, кирәкле мәгълүматны бик тиз таба белергә;
- дәреслектә / укый торган китапта бирелгән шартлы билгеләрне укый белергә,кирәкле текстны китапның “Эчтәлек” бүлегеннән карап таба белергә;
- текст белән эшли белергә: әдәби әсәрнең темасын һәм төп фикерен (идеясен, кичерешләрен), төрле тормыш позицияләрен ( карашлар, максат, кәефкә бәйле каралар) аерып алырга;
- төрле текстлар һәм текстка иллюстрацияләр,мәгълүмат алуның берничә чыганагы ( уку китабы, мөстәкыйль эшләү өчен эш дәфтәре һәм хрестоматия; уку китабы һәм сүзлекләр; текстлар һәм текстка иллюстрацияләр, белем алуның башка төрле чыганаклары, Интернет мәгълүматлары) белән берьюлы эшли белергә;
*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*
*-төрле җыентыклар (монография, жанр буенча һәм тематик җыентыклар) ясау алгоритмына; ләкин шул ук вакытта “җыентык” сүзе үзе термин буларак кулланылмый.*

**Регулятив УУГ**

Укучы өйрәнәчәк:

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;

- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамларга;

- үз эшчәнлегеңне контрольгә алырга, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерергә.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *тормыш тәҗрибәсен кулланырга;*

- *эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә.*

**Коммуникатив УУГ**

Укучы өйрәнәчәк:

- аралашырга һәм хезмәттәшлек итәргә;

- бергә утырган иптәшең белән бергә эшләргә; кечкенә төркемнәрдә эшләргә: үзара эшләрне һәм рольләрне бүлешергә, үзеңә бирелгән эшне башкарырга һәм аны гомуми эшнең бер өлеше итәргә;

- тормыш тәҗрибәсен кулланырга;

- күршең белән хезмәттәшлек итәргә;

- үз фикереңне һәм позицияңне формалаштырырга;

- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;

- күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;

- күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга;

- сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә.

*Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *төрле фикерләр һәм карашлар арасында аермалыкларны аңларга, шул фикерләрнең берсенә кушылырга һәм ни өчен икәнлегенең сәбәбен дәлилләргә;*

- *тексттан геройлар әйткән фикерләрнең дөреслеген дәлилли торган фикерләрне табарга.*

**Предмет нәтиҗәләр**

**Сөйләм һәм уку эшчәнлегенең төрләре**

Укучы өйрәнәчәк:

-уку тизлеген арттыра барып, сүзләрне тулы әйтеп кычкырып укырга;

-текст белән беренчел танышканда, өлешләп укыганда һәм кабатлап укыганда эчтән укырга;

-өйрәнгән әсәрләрнең авторларын – әдипләрнең һәм шагыйрьләрнең исемнәрен әйтә белергә,аларның берничә әсәрен атау, сыйныфта укыган әсәрләрнең кыскача эчтәлеген сөйләргә;

-үзеңә ошаган әдәби герой турында сөйләргә;

-геройга карта авторлык мөнәсәбәтен ачыкларга;

-төрле авторларның 3-4 әсәрен (сайлап алып) яттан сөйләргә;

-китап һәм аның элементларында җиңел ориентлашырга ( автор, исеме, эчтәлеге, иллюстрацияләр);

-әсәрләрнең геройларына характеристика бирергә, төрле әсәрләрнең берничә геройларының характерларын чагыштырырга.

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

- *кирәкле китапны сайлый белергә һәм элементлары буенча аның эчтәлеген билгеләргә;*

- *сайлап алган китапларны мөстәкыйль укырга;*

- *укыган әсәрләрең геройларына бәяләмә бирергә;*

- *сүзлек белән мөстәкыйль эшләргә.*

**Әдәбиятбелеменә кереш**

**Сәнгатьнең төрле төрләренә караган әсәрләр белән эшләү (әдәбият, рәсем сәнгате, гамәли сәнгать,сынлы сәнгать, музыка һ.б)**

Укучы өйрәнәчәк:

-хайваннар турындагы, көнкүреш һәм тылсымлы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белергә;

-әкиятләрне хикәяләрдән аерырга;

-авторлар иҗат иткән әсәрләрдә тел-сурәтләү чараларын таба һәм атый белергә( чагыштыру, сынландыру, гипербола, каршылык, фигуралар, кабатлау)

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

*-хайваннар турындагы әкиятләрдәге вакыйгаларның вакыт аралыгында үсешен;*

*-әкиятләрне әдәби әсәрләр белән чагыштырырга.*

**Иҗади эшчәнлеге элементлары**

Укучы өйрәнәчәк:

-укыганның эчтәлеген аңларга,тиешле интонацияне, уку темпын һәм тиешле тукталышларны текст эчтәлегеннән чыгып аңлап сайлый белергә;

-программада бирелгән әсәрләрне ишетеп тыңларга һәм эмоциональ аңларга; әсәр турындагы фикерләрне телдән әйтергә(сөйләргә);

-әдәби текстларны, музыка, сынлы сәнгать әсәрләрен интерпретацияләргә (ишеткән, күргән һәм укыган әсәрләр буенча үзеңнең уйларыңны һәм хисләреңне белдерергә).

*Мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә һәм коллектив белән эшләү барышында укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:*

*- шигъри һәм чәчмә әсәрләрне сәнгатьле итеп кычкырып укырга;*

*- дәреслектәге иллюстрацияләрне карарга, музыкаль әсәрләрне тыңларга, аларны әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләренең эчтәлеге белән чагыштырырга, аларга салынган фикер, хисләр һәм кичерешләрне аңларга;*

*- әдәби, музыкаль, сынлы сәнгать әсәрләрен анализлау барышында, телдән һәм язмача (фикерләрне язу яки кыска сочинениеләр формасында) үзеңнең шәхси кичерешләрең һәм күзәтүләрең белән уртаклашырга.*

**4нче сыйныф**

**Шәхси нәтиҗәләр**

Чыгарылыш сыйныф укучысында формалашачак:

-туган илгә мәхәббәт, туган телгә сакчыл караш;

-милли үзаң;

-укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш;

-әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш;

-кешеләр белән аралаша белү культурасы.

*Чыгарылыш сыйныф укучысы формалашуга мөмкинлек алачак:*

*- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;*

*- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып- белү күнекмә:**

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү (төп текст, астөшермә һ.б.), өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

— бер мәгълүматны икенче төрле итеп үзгәртә алу (план төзү, таблица, схема);

— әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;

— әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стилен җиткерү;

— татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән таныштыру;

**Регулятив күнекмә:**

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;

- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

**Коммуникатив күнекмә:**

— төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
— үз фикерен тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү;
— бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
— күмәк эш вакытында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;
— укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә алу;
— үз фикерләрен телдән һәм язма формада җиткерә белү;
— башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;
— иптәшләрекаршындатөрлетемаларгачыгышясау.

**Предмет нәтиҗәләр**

**<u>Халык авыз иҗаты әсәрләре</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- халык иҗаты һәм автор әсәрләре турында тулы күзаллау булдырып,  халык иҗаты әсәрләрен автор әсәрләреннән аера белергә;
-тылсымлы, хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне, тормыш- көнкүреш әкиятләрен аерырга;
-әкият белән хикәяне аерырга;
-әсәрдә сурәтләү чараларын табарга (чагыштырулар, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру).

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-мифлар, төрле халыклар әкиятләрендә аларның бирелешен өйрәнергә;
-төрле халыклар әкиятләрендә географик тарихи атамаларның бирелешен ачыкларга

**<u>Автор әсәрләре</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

**Әдәби әсәр тексты белән эш**

әсәрнең исемен аның эчтәлегенә мөнәсәбәтле рәвештә аңлау;
- әсәр геройларының эш-гамәлләренә әхлак кагыйдәләре нормаларыннан чыгып бәя бирү;
-туган ил, Ватан төшенчәсен аңлау;
-төрле халыкларның фольклорында тема, идея, геройларның охшашлыгы.;
-әдәби әсәр эчтәлеген сөйләүнең төрләрен (тулы, сайлап, кыскача – төп фикерне әйтү) үзләштерү;

Текстның эчтәлеген тулысынча сөйләү: бирелгән өзектәге төп фикерне ачыклау, кирәкле сүзләрне билгеләү, исем кушу, эпизодның эчтәлеген тулысынча сөйләү, һәрбер өлешнең һәм текстның төп фикерен билгеләү, һәр өлешкә һәм тулаем текстка исем кушу, тексттагы җөмләләрне атау, сорау җөмлә яки үзләре телгән форма кулланып, план төзү.

Бирелгән өзек эчтәлеген сайлап сөйләү: геройга характеристика бирү (кирәкле сүзләрне тексттан сайлау), вакыйга буенча урынны сурәтләү (урынны сурәтләгән сүзләр, сүзтезмәләрне тексттан алып).

Төрле әсәрдәге охшаш ситуацияләрне, геройларны табу, чагыштыру.

**Балалар китабы белән эш**

Россиядә яшәүче төрле милләт халыкларының авыз иҗаты әсәрләре. XIX–XX гасырда яшәгән классик язучыларның (шул исәптән балалар язучыларының да) әсәрләрен өйрәнү. Чит ил һәм хәзерге көн язучыларының кече яшьтәге мәктәп баласы аңлый алырлык әсәрләрен бирү.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

укытучы ярдәмендә әдәби әсәрнең сәнгати үзенчәлекләрен билгеләү;
- халык авыз иҗаты әсәрләренең гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтүен;
- Россия халыклары мисалында әдәбиятта төрле милләт халыкларының туган илгә мәхәббәте турында күзаллау булдыру ачыклау;
-телнең сурәтләү чараларын кулланып, мөстәкыйль рәвештә текстны күз алдына китерү: укытучы сораулары буенча, әсәрнең лексик үзенчәлекләрен истә тотып, эпизодларны бер-бер артлы искә төшерү, иллюстрацияләр буенча сөйләү, эчтәлеген сөйләү;

Сәнгатьлелек тудыру чараларын кулланып, бирелгән текстгагы геройга характеристика бирү. Әсәрдән геройны һәм вакыйгаларны характерлаган сүзләрне табу. Укытучы ярдәмендә катнашучыларның эш-гамәлләренең мотивларын билгеләү, аларны анализлау, чагыштыру. Геройларның эш-гамәлләрен капма-каршылыгы яки охшашлыгы буенча чагыштыру. Текстны анализлау барышында автор билгеләмәләре, геройның исеме аша авторның аңа мөнәсәбәтен ачыклау. Әсәр героеның портретын, характерын аның эш-гамәлләре һәм сөйләме аша бирү.

**<u>Мәсәлләр</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү һәм моральдән торуын аңларга;

-мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы күрә белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-мәсәл әсәрләренең гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтүен;

**<u>Әдәби жанр</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

**Төрле стильдәге текстлар белән эш**

-төрле стильдәге – әдәби, дәреслек, фәнни-популяр текстлар турында гомуми күзаллау булдыру, аларны чагыштыра белү. Бу төр текстларның максатларын билгеләү; -фольклор текстының үзенчәлекләрен табу;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-текстны төрле җөмләләр тезмәсеннән гамәли аеру;

-әсәрнең исеменә һәм бизәлешенә карап, эчтәлеге турында белә алу.

-текстның темасын, төп фикерен, төзелешен ачыклау; -текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, аларны исемләү.

-төрле мәгълүмат белән эшли алу;

- текст буенча сорауларга җавап бирү, тема буенча чыгыш ясау, иптәшеңнең чыгышын тыңлау, әңгәмә вакытында, текстны кулланып, җавапларны тулыландыруда катнашу.

-төрле белешмә һәм иллюстратив-сәнгать материалларыннан файдалану.

**<u>Библиографик культура</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

Россиядә һәм татарларда беренче китаплар, аларның басыла башлау тарихы турында гомуми күзаллау;

- уку китабы, әдәби әсәр, белешмәлекләр;

-китап элементлары: эчтәлеге яки бүлекләр исемлеге, титул бите, аннотация, иллюстрацияләр;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-китапта бирелгән мәгълүмат төрен ачыклау: фәнни, әдәби (тышкы билгеләренә һәм анда бирелгән белешмә-иллюстратив материал);

- китап типларын ачыклау: әсәр, җыентык, сайланма әсәр, вакытлы матбугат, белешмәлекләр (сүзлек, энциклопедия);

-бирелгән исемлек, картотека буенча китап сайлый белү;

-*алфавит каталогыннан файдалану.*

-яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмә материалларны мөстәкыйль рәвештә куллана белү;

**<u>Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

**Тыңлау (аудирование)**

-ишеткән сөйләүне кабул итү (әңгәмәдәшеңнең фикерләрен, төрле текстларны укыганда тыңлый белү). Сөйләм барышында әйтелгән фикерне аңлау, ишеткән әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләү;

**Уку. Кычкырып уку**

-иҗекләп укудан әкренләп йөгерек, аңлап, сүзләп укуга күчү;
-уку тизлеген даими рәвештә арттыра бару; текстның мәгънәсен тулы күләмдә аңларлык дәрәҗәгә җиткерү;
**Эчтән уку**
-яшь үзенчәлекләренә туры килгән күләмдәге һәм жанрдагы әсәрләрне эчтән укыганда мәгънәсен аңлап җиткерү;
- уку төрләрен билгели белү (өйрәнү, танышу, карап чыгу, сайлап уку). Тексттан тиешле мәгълүматны таба белү. Фактлар, тасвирлау, өстәмә фикерләр белән тулыландырып уку;
***Язма сөйләм культурасы***
-язма сөйләм нормалары: эчтәлекнең әсәр исеменә туры килүе. Язма сөйләмдә телнең сәнгати сурәтләү чараларын: синоним, антоним, чагыштыруларны куллана белү.
**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
сөйләмдә куелган максатны аңлый алу, дөрес, фәнни яктан танып-белү, әдәби әсәрләрне тыңлаганнан соң сораулар куя белү;
-укыганда орфоэпик һәм интонацион нормаларны саклау;
- җөмләләрне укыганда тыныш билгеләрен интонация белән аера белү;
- төрле төрдәге һәм типтагы текстларның мәгънә үзенчәлекләрен аңлау, аларны интонация ярдәмендә бирү; -тексттан тиешле мәгълүматны таба белү;
- фактлар, тасвирлау, өстәмә фикерләр белән тулыландырып уку;
-*бирелгән тема буенча хикәя, бәяләмә төзү.*

**Уку предметының эчтәлеге.**
**1 нче сыйныф**

| № | Бүлекләрнең исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Сөйләм һәм уку эшчәнлегенең төрләре** | Сөйләмне ишетеп аңлау, текстны кабул итү, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү, эчтәлек буенча ишетеп сораулар төзү, вакыйгаларның эзлеклеген төзү. | 6 |
| 2 | **Ишетеп аңлау (аудирование)** | Яңгыраган сөйләмне ишетеп аңлау; укытучы һәм сыйныфташлары кычкырып укыганны, иптәшләре сөйләгәнне, үзенә бирелгән сорауларны кабул итү. | 4 |
| 3 | **Уку. Кычкырып уку** | Иҗекләп укудан сүзләп укуга күчү һәм уку тизлеген үстерә бару; кычкырып уку, чылбырлап уку, рольләргә бүлеп уку теләге формалаштыру; сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү. | 3 |
| 4 | **Эчтән уку** | Зур булмаган текстларны мөстәкыйль укый белү; сайлап уку барышында өйрәнелә торган тексттан һәм сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны таба белү. . | Әлеге бүлекләрнең эчтәлеге, башка бүлекләргә карап, ел ләвамында комплекста тормышка ашырыла |
| 5 | **Әдәби әсәр тексты белән эшләү** | Сорау һәм биремнәргә нигезләнеп текстны аңлау һәм фикер алышу. | |
| 6 | **Уку текстлары һәм фәнни-популяр текстлар белән эш** | Текст эчтәлеген аңлау; текст эчендә өлешләрне, әһәмиятле сүзләрне табу. | |
| 7 | **Төрле төрдәге һәм жанрдагы текстлар белән эшләү** | Әсәрнең халык авыз иҗатына караганын яки автор әсәре икәнлеген аера белү; текстларның жанр үзенчәлекләрен аңлау (тылсымлы әкият, аптыраткыч-йөдәткеч әкият, хикәя, бишек җыры, гимн һ.б.). | |
| 8 | **Библиографик культура формалаштыру** | Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: эчтәлектән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп таба белү. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | файдалану. Балалар китабы белән эшләү. Катапның төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. | |
| 9 | **Сыйныфтан тыш уку** | Укучыларны әдәби китапларны мөстәкыйль укый алу өчен әзерләү; балаларда әдәби китаплар укуга теләк булдыру. | |
| 10 | **Халык авыз иҗаты** | “Халык авыз иҗаты” төшенчәсен аңлау, кече фольклор әсәрләре (санамышлар, табышмаклар, тизәйткечләр, мәкальләр, бишек җырлары; тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турындагы әкиятләр) жанрлары турында белемнәрен системалаштыру. | |
| 11 | **Сөйләм** | Монологик сөйләмнең төрләрен үзләштерү; эчтәлекне тулы һәм кыскартып сөйли белү; диалогик аралашуның үзенчәлекләрен үзләштерү; иптәшеңнең сөйләмен тыңлый һәм аның сөйләменә карата үз фикереңне белдерү; Текстка һәм шәхси тәҗрибәгә нигезләнеп, текст турында үз фикереңне әйтү. | 9 |
| 12 | **Әдәби әсәр тексты белән эшләү** | Сөйләменә һәм эш-гамәлләренә карап, геройның характерын билгели алу, геройның үсешен күзәтү. | 1 |
| 13 | **Иҗади эшчәнлек элементлары** | Әдәби әсәрләрне (яки өзекләрне) рольләргә бүлеп яки чылбырлап уку; поэзия тиешле интонацияне дөрес сайлап һәм тиешле урында тукталышлар ясап укый белү. | 5 |
| 14 | **Балаларның уку даирәсе** | Халык авыз иҗаты әсәрләре; фольклорның кече жанрлары (бишек җырлары, санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар, каргыш-теләкләр); халык әкиятләренең барлык төрләре, мәкальләр һәм әйтемнәр; автор әсәрләре, мәсәлләре; безнең илнең 19 – 20 нче гасыр әдәбияты классикларының әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, шигырь формасында язылган тылсымлы әкиятләр, повестьлар). | 4 |
